**Исполнительный комитет Тюгеевского сельского поселения Заинского муниципального района Республики Татарстан**

ул. Центральная, д. 8, с. Тюгеевка, Заинский район, 423507

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлегенең башкарма комитеты**

Үзәк урамы, 8 нче йорт, Төги авылы, Зәй районы, 423507

Телефон, факс 60-5-48. Электронный адрес: Turg.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**
**15.11.2022** **№ 43**

**Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 16 мартындагы номерлы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 16 мартындагы 31 номерлы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаның электрон формасы кырларын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал гаризаның электрон формасы кырлары дөрес тутырылмауны ачыклаганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры электрон формада хәбәр итү аша мәгълүмат бирелә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлекләре торак пунктларындагы мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Т.В. Попова**